**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

чираттан тыш утырыш
**КАРАРЫ**

16 нчы февраль 2021 ел **№ 41** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районының административ
комиссиясен төзү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елның 30 декабрендәге 11/13-09/6750 номерлы хатын карап, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетын административ комиссия төзү өчен вәкаләтле җирле үзидарә органы итеп билгеләргә.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре чикләрендә:

административ комиссия төзи;

административ комиссия составын раслый;

административ комиссиянең эш регламентын раслый.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов